РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2021 елның 23 июле 277№

Әлки муниципаль районының Психологик-медик–педагогик комиссия турында нигезләмәсен раслау турында

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 20 сентябрендәге «Психологик-медик-педагогик комиссия турында нигезләмәне раслау хакында»1082 номерлы боерыгы нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 1 нче кушымта нигезендә Әлки муниципаль районының Психологик-медик-педагогик комиссиясе турында нигезләмәсен расларга.
2. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 24 июнендәге 303 номерлы карары белән расланган Әлки муниципаль районының психологик-медик-педагогик комиссия турында нигезләмәсен үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И.В.Юсупов.

Хәбибуллина Л. Р.
8(84346)21601

Әлки муниципаль районы Башкарма
комитетының 2021 елның 23 июлендәге
277 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Муниципаль психологик-медик-педагогик комиссия турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Психологик-медик-педагогик комиссия (алга таба ПМПК) турында нигезләмә, балаларга комплекслы психологик-медик-педагогик тикшерү үткәрү тәртибен дә кертеп, психологик-медик-педагогик комиссия эшчәнлеген регламентлый.

1.2. ПМПК ведомствоара булып тора.

1.3. ПМПК үз эшчәнлегендә Бала хокуклары турында БМО Конвенциясенә, РФ һәм ТР гамәлдәге законнарына, РФ һәм ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының, РФ Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының, ТР сәламәтлек саклау министрлыгының норматив-хокукый, методик һәм башка документларына, әлеге Нигезләмәгә таяна.

Психологик-медик-педагогик комиссия (ПМПК) Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 20 сентябрендәге 1082 номерлы боерыгы белән расланган Психологик-медик-педагогик комиссия турында Ннигезләмәгә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2017 елның 31 мартындагы 542/17 номерлы боерыгы белән расланган Психологик-медик-педагогик комиссияләрнең эш тәртибенә таяна.

1.4. ПМПК эшенә методик җитәкчелек "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ (алга таба - Мәгариф идарәсе) тарафыннан башкарыла.

1.5. ПМПК Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән төзелә, анда белгечләр составы раслана.

1.6. ПМПК гариза кергән саен утырышлар үткәрә (аена 1-2 утырыш).

2. ПМПКнең максаты һәм төп бурычлары

2.1. ПМПК физик һәм (яки) психик үсештәге үзенчәлекләре һәм (яки) үз-үзләрен тотышында тайпылышлар булган балаларны үз вакытында ачыклау, аларны комплекслы психологик-медик - педагогик тикшерү (алга таба-тикшерү) уздыру һәм аларга психологик-медик-педагогик ярдәм күрсәтү һәм аларны укыту һәм тәрбияләүне оештыру буенча рекомендацияләр әзерләү, шулай ук элегрәк бирелгән тәкъдимнәрне раслау, аныклау һәм үзгәртү максатлында төзелә.

2.2. ПМПК эшчәнлегенең төп юнәлешләре булып тора:

- 18 яшькә кадәрге балаларның физик һәм (яки) психик үсешендә үзенчәлекләрен һәм (яки) үз-үзләрен тотышында тайпылышларын үз вакытында ачыклау максатыннантикшерү үткәрү;

- тикшерү нәтиҗәләре буенча балаларга психологик-медик-педагогик ярдәм күрсәтү һәм аларны укыту һәм тәрбияләүне оештыру буенча тәкъдимнәр әзерләү, әлеге тәкъдимнәрне раслау, төгәлләштерү яисә үзгәртү;

- сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәм (яки) девиант (иҗтимагый куркыныч) үз-үзен тотышы булган балаларны тәрбияләү, укыту һәм коррекцияләү мәсьәләләре буенча балаларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) , мәгариф оешмалары, социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмалар, медицина оешмалары, башка оешмалар хезмәткәрләренә консультатив ярдәм күрсәтү;

- инвалид баланы реабилитацияләүнең индивидуаль программасын эшләүдә медик-социаль экспертиза учреждениеләренә ярдәм күрсәтү;

- мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм инвалид балалар турында мәгълүматларны исәпкә алу;

- балаларны Республика ПМПКенә җибәрү.

3. ПМПК составы һәм аның эшен оештыру

3.1. Балаларны комплекслы тикшерүне тәэмин итү максатларында ПМПК составына түбәндәге белгечләр керә: укытучы-логопед, укытучы-дефектолог, педагог-психолог, балалар психиатры.

3.2. ПМПКне Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән билгеләнә торган җитәкче җитәкли.

3.3. ПМПК белгечләре Мәгариф идарәсе, мәгариф оешмалары, психологик-педагогик хезмәт биналарында эш алып баралар, кирәк булганда тикшерү өчен балаларның яшәү урынына баралар.

3.4. ПМПКгә балаларны кабул итү ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) язмача гаризасы яисә социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары, медицина оешмалары, башка оешмалар юнәлеше буенча аларның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) язмача ризалыгы белән гамәлгә ашырыла.

3.5 ПМПКгә үз эшчәнлегендә хокук бирелә:

- барлык кирәкле документларны таләп итәргә (шул исәптән ПМПКгә табиб-психиатрдан киңәйтелгән диагноз куелган юнәлеш бирү мәҗбүри санала);

- белем бирү оешмаларында, шулай ук гаиләдә (баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) ризалыгы белән) балаларны укыту һәм тәрбияләү өчен кирәкле шартлар тудыру буенча ПМПК рекомендацияләрен исәпкә алуны гамәлгә ашырырга.

3.6. Балаларны тикшерү һәр белгеч тарафыннан шәхсән яки берничә белгеч тарафыннан бер үк вакытта үткәрелә.

3.7. Балаларның әлеге тикшерүләре беркетелә. Баланы шәхси тикшерү мәгълүматлары нигезендә аның үсешендәге тайпылыш характеры турында коллегиаль бәяләмә төзелә һәм баланың психофизик мөмкинлекләрен исәпкә алып, баланы тәрбияләү һәм укытуны оештыру формасы һәм (яки) баланы Республика ПМПКенә җибәрү турында коллегиаль карар (рекомендация рәвешендә) кабул ителә.

3.8. Беркетмә һәм коллегиаль бәяләмә ПМПК составы тарафыннан имзалана, Мәгариф идарәсе мөһере белән раслана.

3.9. Ата-аналарга (законлы вәкилләргә) тәкъдимнәр белән ПМПК коллегиаль бәяләмәнең күчермәсе яки имза куйдырып коллегиаль бәяләмәнең оригиналы бирелә.

Мәктәп яшендәге балалар өчен муниципаль ПМПК коллегиаль бәяләмәсе баланы Татарстан Республикасы сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренә җибәрү өчен нигез булып тормый. Әлеге оешмаларны комплектлау Республика ПМПК бәяләмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.10. ПМПКдә түбәндәге документлар алып барыла:

а) балаларны тикшерү өчен яздыру журналы;

б) тикшерү узган балаларны исәпкә алу журналы;

в) тикшерү узган бала картасы;

г) баланы тикшерү беркетмәсе (алга таба - беркетмә).

3.11. Тикшерү беркетмәсе мәгариф идарәсендә 18 яше тулганнан соң кимендә 10 ел саклана.

3.12. Тикшерү узган балаларны тикшерүгә һәм исәпкә алуга балаларның алдан язылу журналлары аларны алып бару тәмамланганнан соң кимендә 5 ел Мәгариф идарәсендә саклана.

3.13. Балаларны ПМПКендә тикшерү үткәрү, тикшерү нәтиҗәләре, шулай ук ПМПКдә балаларны тикшерү белән бәйле башка мәгълүмат конфиденциаль. Күрсәтелгән мәгълүматны, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, өченче затларга баланың ата-анасының (законлы вәкилләренең) язма ризалыгыннан башка бирү рөхсәт ителми.

3.14. Балаларны тикшерү, балаларга һәм аларның ата-анасына (законлы вәкилләренә) ПМПК белгечләре тарафыннан консультацияләр бирү түләүсез гамәлгә ашырыла.

3.15. Балаларның ата-анасы (законлы вәкилләре) өчен ПМПК бәяләмәсе тәкъдим итү характерына ия.

3.16. ПМПК бәяләмәсе, аны имзалау көненнән башлап календарь ел дәвамында гамәлдә.

## 4. ПМПК җитәкчесенең вазыйфаи бурычлары

4.1. ПМПК җитәкчесе комиссия эшен оештыра.

4.2. Җитәкче ПМПК документларын алып бара, узган уку елындагы эш нәтиҗәләре буенча хисап төзи һәм республика ПМПКенә мәгълүматлар бирә.